**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы бишенче чакырылыш Советының
КАРАРЫ

2025 елның «15» октябреннән № 2-7

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатураларны караганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе итеп Фасахов Ринат Рифгать улын билгеләп куярга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Фасахов Ринат Рифгать улы белән контракт төзергә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны билгеләп кую турында" 23.09.2025 елның 1-5 номерлы карарын 2025 елның 15 октябреннән үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский